# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы Конституция суды турында"
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 5 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Конституция суды турында" 1992 елның 22 декабрендәге 1708-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1998 елның 30 октябрендәге 1840 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7 – 8; 2003, № 10; 2006, № 2 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш); 2008, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфасына кандидатка карата куела торган таләпләр**

1. Россия Федерациясенең түбәндәге гражданы Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы була ала:

1) 25 яшьтән дә яшьрәк булмаган, югары юридик белеме булган, юридик белгечлеге буенча эш стажы кимендә биш ел булган;

2) хөкем ителүе булмаучы яисә булмаган йә реабилитацияләү нигезләре буенча җинаяти эзләрлекләве туктатылган;

3) чит дәүләт гражданлыгы йә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә яшәүгә рөхсәте яисә даими рәвештә яшәүгә хокукын раслый торган бүтән документы булмаучы;

4) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылмаган;

5) алкоголизмнан, наркоманиядән, токсикоманиядән, хроник һәм озакка сузылган психик тайпылышлардан дәвалануга бәйле рәвештә наркология яисә психоневрология диспансерында исәптә тормаучы;

6) судья вәкаләтләрен башкаруга комачауларлык бүтән авырулары булмаучы.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфасына түбәндәгеләр кандидат була алмый:

1) җинаять кылуда шик белдерелүче яисә гаепләнүче зат;

2) Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе яисә Рәисе урынбасары белән якын туганлык һәм кода-кодачалык мөнәсәбәтләрендә булучы зат (ире яисә хатыны, ата-анасы, балалары, бертуган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре, бабалары, әбиләре, оныклары, шулай ук ире яисә хатынының ата-анасы, балалары, бертуган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре).";

2) 10 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында Татарстан Республикасы дәүләт телләренең берсендә түбәндәге эчтәлекле ант итә: "Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вазыйфаларын гадел һәм намус белән үтәргә, бу чакта, Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә буйсынып, Татарстан Республикасының конституциячел корылышын якларга тантаналы рәвештә ант итәм".";

3) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"11 статья. **Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына карата куела торган таләпләр**

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) дәүләтнең бүтән вазыйфаларын, дәүләт хезмәте вазыйфаларын, муниципаль вазыйфаларны, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләргә, арадашчы судья, арбитр булырга;

2) сәяси партияләрдә торырга, шушы партияләргә матди ярдәм күрсәтергә һәм аларның сәяси акцияләрендә һәм бүтән сәяси эшчәнлектә катнашырга;

3) сәяси партияләргә һәм бүтән иҗтимагый берләшмәләргә карата үз мөнәсәбәтен гавами белдерергә;

4) эшкуарлык эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлары аша шөгыльләнергә, шул исәптән оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез рәвештә хуҗалык итүче субъектка идарә итүдә катнашырга;

5) шөгыльләнүе судья вазыйфаларын үтәүгә комачауламаслык һәм, Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе ризалык бирмәгән булса,

утырышта катнашмау өчен мөһим сәбәп булмаслык укыту, фәнни һәм бүтән иҗади эшчәнлектән гайре, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Бу чакта, Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яисә Татарстан Республикасы Конституция суды белән чит дәүләтләрнең тиешле судлары, халыкара һәм чит ил оешмалары белән үзара сөйләшеп килешүләре нигезендә бүтәне каралмаган булса, әлеге эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

6) физик яисә юридик затларның эшләре буенча ышанычлысы яисә вәкиле (законлы вәкиллек очракларыннан гайре) булырга;

7) судта карау предметы булган мәсьәлә буенча суд акты закон көченә кергәнче, шушы мәсьәлә буенча гавами фикерләр әйтергә;

8) судья вазыйфаларын башкаруга бәйле булмаган максатларда хезмәт эшчәнлеге өчен билгеләнгән матди-техник, финанс һәм мәгълүмат тәэминаты чараларыннан файдаланырга;

9) судья вазыйфаларын башкаруга бәйле булмаган максатларда федераль закон нигезендә файдаланылуы чикләнгән мәгълүматка кертелгән белешмәләрне яисә судья вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган хезмәт мәгълүматын башкаларга җиткерергә яисә алардан файдаланырга;

10) судья вазыйфаларын башкаруга бәйле рәвештә Россия Федерациясе законнары белән каралмаган бүләкләүләрне (ссудалар, акчалата һәм бүтән бүләкләү, хезмәт күрсәтүләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү) физик һәм юридик затлардан алырга. Беркетмә гамәлләренә, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми гамәлләргә бәйле рәвештә судья тарафыннан алынган бүләкләр федераль милек яисә Татарстан Республикасы милке дип таныла һәм акт буенча судья тарафыннан Татарстан Республикасы Конституция судына җибәрелә, моңа законнарда каралган очраклар керми. Беркетмә гамәленә, хезмәт командировкасына һәм башка рәсми гамәлгә бәйле рәвештә алган бүләген тапшырган судья аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

11) чит дәүләтләрнең, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен (фәнни һәм спорт исемнәреннән гайре), бүләкләүләрен һәм бүтән төрле аерымлык тамгаларын Татарстан Республикасының Судьялар квалификация коллегиясе рөхсәтеннән башка кабул итәргә;

12) физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән Россия Федерациясе территориясеннән читкә хезмәт командировкаларына барырга, Россия Федерациясе законнары, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләре яисә Татарстан Республикасы Конституция суды белән чит дәүләтләрнең тиешле судлары, халыкара һәм чит ил оешмалары белән үзара сөйләшеп килешүләре нигезендә хезмәт командировкаларына бару очракларыннан гайре;

13) Россия Федерациясе законнарында, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәләрендә яисә Татарстан Республикасы Конституция суды белән чит дәүләтләрнең тиешле судлары, халыкара һәм чит ил оешмалары белән үзара килешүләр нигезендә бүтәне каралмаган булса, Россия Федерациясе

территориясендә эшләп килүче чит илләрнең хөкүмәткә карамаган коммерциячел булмаган оешмаларының һәм аларның структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительлек яисә күзәтү советлары, бүтән төрле органнары составына керергә;

14) хезмәт бәхәсен җайга салу максатларында вазыйфаи бурычларын үтәүне туктатырга.";

4) 21 статьяда:

беренче өлештә:

а) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы йә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә яшәүгә рөхсәт яисә даими рәвештә яшәүгә хокукын раслый торган бүтән документ алу;";

б) түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

"11) судья Татарстан Республикасы Конституциясе суды Рәисе яисә Рәисе урынбасары белән якын туганлык һәм кода-кодачалык мөнәсәбәтләрендә (ире яисә хатыны, ата-анасы, балалары, бертуган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре, бабалары, әбиләре, оныклары, шулай ук ире яисә хатынының ата-анасы, балалары, бертуган абый-энеләре һәм апа-сеңелләре) булган очракта.";

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләре әлеге статьяның беренче өлешендәге 1 – 3, 5 – 9, 11 пунктларында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылырга мөмкин.";

5) 22 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы, әлеге Законның 21 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2, 4, 8, 10 һәм 11 пунктларында каралган нигезләр буенча аның вәкаләтләре туктатылган булса, отставкада дип санала.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

ОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2009 елның 3 декабре
№ 57-ТРЗ